| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.12.2025 Казан ш. 5021-р

Газ бүлү челтәренең (газүткәргеч) саклык чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләрен (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 25.09.2014 № 1985-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында” 2015 елның 15 июлендәге № 218-ФЗ Федераль Законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында” 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «СК «ГАЗЖИЛСЕРВИС» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән документациягә туры китереп, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУның хатын (05.12.2025 № 01А-08/2599) истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәрләрен (газүткәргечләр) саклау зоналары чикләрен раслау турында” 25.09.2014 № 1985-р карары (алга таба - № 1985-р

Карар) белән урнаштырылган «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге, Яшел Үзән муниципаль берәмлеге территориясендә булган җир кишәрлекләрендәге саклау зонасына, трасса үзгәртелү белән бәйле газүткәргеч үзгәртеп ясалу сәбәпле, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектлары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә туры китереп, 1070 км. озынлыктагы, инвентарь номеры 37378, реестр номеры 16:20-6.946 булган бүлү газүткәргеченең саклау зонасын үзгәртергә. Инвентарь номеры 37378 булган газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы гомуми мәйданы 1259700,06 кв.м. булып, 251940,012 м озынлыкны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 37378 булган газ бүлү челтәренең эксплуатация срогында өлешчә яки тулысынча газүткәргечләрнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зоналар чикләренең текст һәм график тасвирламасындагы белешмәләргә, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталары координаталары исемлегенә нигезләнеп, № 1985-р Карарга (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 07.04.2023 № 972-р карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1. Яшел Үзән районы территориясендә әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы инвентарь номерлы, «Граница» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «Татарстан Республикасы техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АҖ тарафыннан башкарылган җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасында (планда) булган белешмәләр нигезендә Яшел Үзән районы буенча ЭПУ «Зеленодольскгаз» газ бүлү челтәрләре (газүткәргечләр) объектларының гомуми мәйданы 5,3505555 кв.км булган, 1070,1111 км озынлыктагы саклау зонасын билгеләргә»;

4. Әлеге карарның үтәлеген контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**